| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | с. Тюлячи | КАРАР |
|---|---|---|
| «13» марта 2026 ел. | | № 32 |

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы буенча Россия ФҖҮХИ ҖБИ ФКУ Арча муниципальара филиалының 2026 елның 10 мартындагы 17/ТО/82/12/3-57 номерлы хатын карап, 2025 елның 23 июлендәге № 218-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең Җинаять кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль кодексының 299 ст. беренче өлешенең 7.1 пунктының көчтән чыккан дип тану турында» Федераль законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына (27.01.2014 № 43, 18.02.2016 № 91, 08.11.2016 № 1012, 11.07.2017 № 422, 23.10.2019 № 590, 01.02.2021 № 33, 29.12.2021 № 327, 04.04.2022 № 327, 17.03.2023 № 49, 18.10.2023 № 158, 05.04.2024 № 48, 21.01.2025 № 7, 25.07.2025 № 100, 30.01.2026 № 7 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) карар исеменнән «төзәтү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Теләче муниципаль районы территориясендә хөкем ителүчеләрнен төзәтү һәм мәҗбүри эшләр башкару өчен объектлар һәм эш төрләре исемлеген раславга.»

В) Теләче муниципаль районы территориясендә хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр башкару өчен объектлар һәм эш төрләре исемлеген, күрсәтелгән карар нигезендә, кушымта буенча бирергә;

Г) 2 пунктны төшереп калдырырга;

Д) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Татарстан Республикасы буенча Россия ФҖҮХИ ҖБИ ФКУ Арча муниципальара филиалына хөкем ителүчеләрне әлеге карар белән билгеләнгән урыннарга мәҗбүри эшләргә җибәрергә тәкъдим итәргә."

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем

ителгәннәр өчен җәза үтәү урыннарын билгеләү турында» 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 30 гыйнварындагы 7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

*Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «13» 03 2026 № 32 карарына кушымта*

**РАСЛАНДЫ**
Теләче муниципаль районын Башкарма комитетының
2012 елның 24 апрелендәге № 398 номерлы карары белән

**КИЛЕШТЕРЕЛДЕ**
Татарстан Республикасы буенча
Россия ФҖҮХИ ҖБИ ФКУ Арча
муниципальара филиалы башлыгы
урынбасары
__________ Р.М. Хафизов

«___»_________20__

Теләче муниципаль районы территориясендә хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр башкару өчен объектлар һәм эш төрләре исемлеге

| № | Оешма исеме | Объектлар һәм территорияләр урнашуы исемлеге | ИНН | Башкарыла торган эш төре | Устав (дәүләтнеке булмаган оешмалар өчен) нигезендә оешма эшчәнлегенең юнәлеше |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты | Әбде авыл җирлеге (Әбде Тактамыш, Ташлыяр торак пунктлары) | 1619004394 | территориял әрне, торак пунктларны җыештыру, яшелләндерү, төзекләндерү | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 2 | Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты | Айдар авыл җирлеге (Айдар, Субаш, Борчаклы Яз т.п.) | 1619004436 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге башкарма комитеты | Алан авыл җирлеге (Алан, Балыклы, Күкчә, Ключище т.п.) | 1619004387 | - хезмәт (административ) биналарын җыештыру;<br><br>- йөк төяү-бушату эшләре;<br><br>- биналар, корылмалар, юлларны ремонтлау (төзү) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 4 | Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге башкарма комитеты | Баландыш авыл җирлеге (Баландыш, Урта Мишә торак пунктлары) | 1619004362 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 5 | Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге башкарма комитеты | Олы Нырсы авыл җирлеге (Олы Нырсы т.п., Кече Нырсы, Кече Мирәтәк, Иске Карабаян, Карабаян, Тәмте) | 1619004450 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 6 | Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитеты | Олы Мишә авыл җирлеге (Олы Мишә, Түбән Саурыш, Олы Саурыш, Җәнәй т.п.) | 1619004468 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 7 | Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты | Олы Мәтәскә авыл җирлеге (Олы Мәтәскә, Лесной, Югары Мәтәскә, Ямбулат, Тәмте Мәтәскә торак пунктлары) | 1619004411 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 8 | Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге (Югары Кибәхуҗа, Максабаш, Тәрек-Тәмте т.п.) | 1619004443 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 9 | Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге (Кече Кибәхуҗа, Казаклар, Олы Кибәхуҗа т.п.) | 1619004429 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 10 | Теләче муниципаль | Иске Җөри авыл җирлеге | 1619004404 | | Җирле үзидарә |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты | (Иске Җөри, Олы Тиләҗе, Караширмә, Орымширмә, Яңа Җөри, Алан Җөри т.п.) | | | органнары эшчәнлеге |
| 11 | Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башкарма комитеты | Теләче авыл җирлеге (Теләче, Комаровка, Ачы, Екатериновка т.п.) | 1619004203 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 12 | Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитеты | Үзәк авыл җирлеге (Үзәк, Шармаш, Сауш, Алга, Петровский, Пановая Гора т.п.) | 1619004370 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |
| 13 | Теләче муниципаль районы Шәдке авыл җирлеге башкарма комитеты | Шәдке авыл җирлеге (Шәдке, Югары Мирәтәк, Олы Мирәтәк, Удельный Мирәтәк) | 1619004482 | | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев